ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел. № 32/9

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм анын составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү инициативасын тәкъдим итү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы» 131- ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 13 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм анын составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү инициативасын кушымтада каралган тәртиптә тәкъдим итәргә
2. Тукай муниципаль районы һәм Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм анын составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү буенча, законда билгеләнгән тәртиптә, халык фикерен өйрәнүне тәкъдим итәргә.
3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртүгә карата шәһәр халкы фикерен ачыклау максатынла 2019 елның 12 сентябрендә 14:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча җәмәгать тыңлауларын уздырырга: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 400 зал.
4. Фикер алышуга чыгарылган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу хакында гаризалар язмача 2019 елның 10 сентябренә кадәр эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр (төшке ял вакыты 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр) түбәндәге адрес буенча

кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты,233 каб, тел. 30-59-72.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына:

1) билгеләнгән тәртиптә һәм әлеге Карар нигезендә билгеләнгән вакытта җәмәгать тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә;

2) җәмәгать тыңлаулары үткәрү хакында хәбәрне «Челнинские известия» газетасында һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.


6. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының 32/9 санлы
Карарына кушымта
01 август, 2019 ел

Муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртүне исәпкә алып ясалган
КАРТА-СХЕМА




Шартлы билгеләр:

– Тукай муниципаль районы һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре
– муниципаль берәмлекләрпнең чикләре
– А-Б – Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
– җирлекләрнең административ үзәкләре
– торак пунктлар
– Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенә кертелүче өлеше